РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Тумутукского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ул. Тельмана д.62Б
с. Тумутук, Азнакаевский район, 423316
Тел (Факс):(8–85592)34-3-42

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге
Советы
БАШЛЫГЫ

Тельман урамы, йорт 62Б
Тымытык авылы, Азнакай районы,423316
Тел(факс):(8–85592)34-3-42

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 09 октябрь 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 27.10.2020 ел Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 27 октябрь 2020 ел 10.00 сәг.тән 16.00 сәг.кадәр;

- үткәрү урыны – Әгер авылы, Совет ур., 27 йорт, Әгер авыл мәдәният йорты залы ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгер авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 19 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар

белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт;

- сайлау хокукына ия булган Әгер торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Әгер торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар жыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Тымытык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентларның 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум итеп билгеләп, бер тапкыр түләүне киметүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Әгер авылында янгын сүндерү техникасын карап тоту (машина йөртүченең хезмәте өчен килешү буенча түләү);
- Әгер авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында кече хәбәр итү системасын сатып алу һәм урнаштыру;
-Әгер авылында «Халыкара хатын-кызлар көне» «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», инвалидлар декадасы, «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Әгер авылының М.Җәлил урамы зиратында контейнер мәйданчыклары һәм аларга киртәләр урнаштыру өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыкларын һәм аларның нигезен урнаштыру.

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылы, Тельман ур., 62Б йорт, Әгер авылы, Совет ур., 27 йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: Э.Х.Гыйләҗева